**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**АПАС МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ЧҮРИ-БУРАШ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

# КАРАРЫ

2020 ел, 8 апрель №147

## Чүри-Бураш авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль законы, муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы Кодексы,Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы «Чүри-Бураш  авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Чүри-Бураш авыл җирлеге Советы **к а р а р  и т т е**:

1.Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Чүри-Бураш авыл җирлеге Советының 2016 елның 12 февралендәге «Чүри-Бураш авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турындагы нигезләмә» 27 номерлы карарының «Чүри-Бураш авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турындагы нигезләмә» дигән 1 нче кушымтасына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 3.2 пунктының бишенче абзацында «биш» сүзен «дүрт» сүзенә алмаштырырга.;

2) 3.2 пунктының җиденче абзацын төшереп калдырырга;

3) 3.3 пунктының «муниципаль хезмәт вазыйфалары» сүзләреннән соң «әйдәп баручы,»  сүзен өстәргә.

2. 2020 елның 1 октябренә кадәр Чүри-Бураш авыл җирлегенең Башкарма комитет җитәкчесе урынбасары (сәркәтибе) вазыйфасын биләү өчен түбәндәге квалификация таләпләре куела дип билгеләргә:

һөнәри белем дәрәҗәсенә-урта һөнәри белем булу;

муниципаль хезмәт стажына яки белгечлек буенча эш стажына-кимендә ике ел яки кимендә өч ел.

3.Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында, мәгълүмат стендларында бастырып чыгарырга.

4.Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Чүри-Бураш авыл җирлеге башлыгына йөкләргә.

**Чүри-Бураш авыл җирлеге Башлыгы**
**Чүри-Бураш авыл җирлеге Советы Рәисе** **И.Р. Мифтахов**